ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.11.2020 г. М ө с л и м № 560

**2021 елга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торган ТР Мөслим муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга норматив чыгымнарны 2021 елга расларга.
2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының финанс-бюджет палатасына белем бирү оешмаларын «2021 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2020 елның 26 сентябрендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм әлеге карарның 1 пункты белән расланган белем бирү оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **М.Р. Бәдретдинова**

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
«02» ноябрь 2020 елның
560 нчы номерлы карары белән
расланган

**ТР Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль урнашу | Елына бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, сумнарда |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | авыл җирлеге | 94213 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | авыл җирлеге | 143701 |